**Казан шәһәре Яңа Савин районының**

**“208 нче номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы”**

# Балалар бакчасында театраль эшчәнлек ярдәмендә балаларны татар теленә өйрәту.

**Татар теле тәрбячесе:.**

**Сагдиева Лилия Рашитовнае:**

**С**

**Казан-2019**

**Балалар бакчасында театраль эшчәнлек ярдәмендә балаларны татар теленә өйрәту.**

***“Театр — яктылыкка, нурга илтә,***
***Кире юлга җибәрми, уңга илтә...”***

Театр – сәнгатьнең бер төре. Ул үз эченә әдәбият, музыка, бию,сынлы сәнгатьне берләштерә.Театр -  үзенә тартучы бер төрле сихри дөнья ул.Үзенең тылсымлылыгы, кызыклылыгы белән балаларны һәм без олыларны да үзенә җәлеп итә.Безне үзенең әкияти дөньясына сиздермичә алып кереп китә. Моны истә тотып, мин балалар бакчасында татар телен укыту буенча тәрбияче буларак, театраль эшчәнлекне дәресләрдә актив куллананам. Чөнки балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телләрен  үстерүдә, җәмгыятьтә үзен- үзе тота белергә өйрәтүдә, мәрхәметле һәм сәләтле кеше булып үсүләрендә театральләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә- юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә бу дөньяда яшәргә, үзенең мөгамәләләрен төзергә өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур, әйбәт сөйләшә белүен таләп итә. Сәхнәләштерү уеннарында катнашып, балалар образлар, төсләр, авазлар аша тирә- юнь белән танышалар, ә сораулар балаларны уйларга, анализларга, йомгаклау ясарга мәҗбүр итә.Балалар театрда катнашуны уен буларак кабул итәләр һәм бик зур теләк белән катнашалар. Шулай итеп үзләре дә сизмәстән татар телен өйрәнәләр.

Сәхнә эшчәнлеге нәтиҗәсендә балаларның  диалогик сөйләме баи,
сүзлек запасы активлаша башлый. Өйрәнелгән театраль күренешләр баланың фикерләү сәләтен үстерә, дусларына һәм әти-әниләренә спектакль турында сөйләү ихтыяҗын тудыра. Бу үз чиратында сөйләм телен баетуга, диалогик сөйләм  аша аралаша белүгә, үзенең хис-кичерешләрен  монологик сөйләм ярдәмендә тасвирлауга этәрә.

Театраль әшчәнлекне оештырганда  акыл үсеше белән сөйләм теленең үсеше үзара нык бәйләнештә торуын истә тотып эш итәм. Геройлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләгәндә, баланың сүз байлыгы арта, аваз культурасы, интонацияле сөйләве үсеш ала. Башкарылачак роль баланы чиста, аңлаешлырлык итеп сөйләвен таләп итә. Сәхнәләштерелгән уеннар барышында, баланың геройлар өчен кайгыруын, үзен алар урынына куюын , булышу ысулларын табуын, яхшылык һәм явызлыкка үзенең карашын күрсәтүен күзәтергә мөмкин. Димәк,театраль әшчәнлек баланы төрле яктан үстерә.
Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда, һәр бала үзенең кичерешлә-
рен, тойгыларын, теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга һәм яшьтән үк өйрәтергә кирәк дип уйлыйм. Еш кына без киң белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез. Бу проблемалар булмасын өчен, балалар бакчасында театр кую бик зур булышлык күрсәтә дип уйлыйм.

Театраль уеннар балалар га бик тә ошый. Спектакльләрдә алар зур теләк белдереп катнашалар.Элекке заманнарда ук, бөек фәлсәфәче Сократ : “Баланы көчләп тәрбияләмә, ә уен аша өйрәт.Шул вакытта гына баланың нәрсәгә сәләтле булуын аңларсың “- дип язып калдырган.
Театр аша балалар тирә-юнь , төсләр, авазлар белән танышалар, ә  аларга бирелгән  сораулар  аларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, бала үзе дә сизмичә,аның сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша- яңа сүзләр белән баетыла. Әкиятне укып бетергәч, балаларга нинди дә булса җөмләне тәмамларга, кабатларга, эчтәлеген сөйләргә тәкъдим ителә. Аннан кечкенә хикәяләр алына. Әкренләп монологик сойләм генә түгел, ә диалогик сөйләм дә үсә. Аваз культурасы өстендә эшләнелә. Бала күп нәрсәне исендә калдыра. Аның хәтере үсә. Рольне уйный- уйный, бала әкият дөньясына кереп китә, татар телен истә калдыру җиңеләя.

Театральләштерү эшчәнлеге күрсәтүенчә, бала ялгышырга мөмкин, ә менә әкият герое ялгышырга тиеш түгел. Шуңа күрә балалар әкият уйнаганда, сүзләрен 2–3 мәртәбә тырышыбрак өйрәнәләр. Аларның бу шөгыльләрдән соң хәтерләре яхшыра. Яраткан геройлар балаларга үрнәк булалар.Сәхнәләштерү эшчәнлеге балаларга проблемалы ситуацияләрне чишәргә булыша-  геройлар  аркылы оялчанлыкны, кыюсызлыкны бетерергә, сәнгатьле итеп сөйләргә ярдәм итә. Рольне уйнау, баланы башка персонаж алдында чиста, аңлаешлырак итеп аңлатуны таләп итә. Театр бала өчен якты истәлек, тылсымлы бер дөнья булып кала.
Татар теленә өйрәтү шөгелендә төрле этапларында  театраль уеннарны оештырырга мөмкин.Ул түбәндәге этаплар:
*1 этап*: балаларны яңа сүзләр белән таныштырганда.
*2 этап*: үткән материалны кабатлаганда.
*3 этап:* татар телен сөйләмдә актив кулануны ныгытканда.
***Театраль әшчәнлек үз алдына түбәндәге бурычларны куя*** :
сәхнәләштерү эшчәнлегенә тотрыклы кызыксынуны үстерү;
балаларның сүз байлыгын үстерү ;
дөрес аваз әйтелешен тәрбияләү;

мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонация кебек тәэсирле чараларны кабатлау теләге тудыру.
Балаларның сәхнәләштерү эшчәнлеге иртәнге, кичке сәгатьләрдә, дәреснең бер өлеше булып, шулай ук аерым планлаштырылган дәрес булып та кертелергә мөмкин.

***Сәхнәләштерү эшчәнлеге***:

-курчак театры карау һәм алар буенча әңгәмә оештыру;

-уен- драматизацияләр;

-сәнгатьле итеп сөйләү күнегүләре;

-этика буенча аерым күнегүләрне үз эченә ала.

Ә менә тәрбияче үзе сәнгатьле итеп сөйләү генә түгел, күрә, ишетә белергә,актерлык, режиссерлык осталыгына да әзер булырга тиеш. Тик ул үзенең актерлык осталыгы белән оялчан баланың уйнау теләген бетереп, карауч ыга әйләндерергә тиеш түгел. Балалар ялгышудан куркырга, гел карауч ы гына яки гел катнашучы гына булырга тиеш түгел.

***Рольләргә бүлгәндә төрле алымнар кулланыла***:

-баланың теләге буенча роль сайлау;

-төп рольләргә оялчан балаларны билгеләү;

-карточкалар буенча рольләргә бүлү;

-парлап уйнау.

***Мондаике проблема килепчыгаргамөмкин:***

-һәр балага рольләр җитмәсә нишләргә;

- тискәре рольләрне кем уйнар

Беренче проблеманы балаларны төркемнәргә бүлеп чишепб ула. Ә икенчесен аңлатырга: әкияттә, сәхнәдә барысы да артистлар. Ә артист уңай рольне дә, тискәре рольне дә уйный белергә тиеш. Тискәре рольне уйнау күпкә катлаулырак та, һәр бала тискәре рольне дә, уңай рольне дә уйный белергә тиеш.
Кечкенәләр белән эшләгәндә, мин аларның матур кастюмнарга, әкият геройларына, битлекләргә кызыкканнарына игътибар итәм. Кием алмаштырып үзгәрү алар өчен бик күңелле күренеш. Әкренләп мин аларда сәхнәләштерелгән уеннарга кызыксыну уятам, эчтәлеге зур булмаган курчак театрлары күрсәтә башлыйм. Башта бу уен охшату кебек уздырыла. Мәсәлән, кешеләрнең, хайваннарның аерым гамәлләрен охшатып кабатларга тырышу. (Чыпчыклар канат кагалар, куян төлкене күреп агач астына сикерде яки батыр әтәч юл буйлап атлый). Тора-бара, балаларны спектакльдәге аерым фразаларны кабатларга теләк уятам. Балаларны курчак театрының төрле төрләре белән таныштырып, аларны кечкенә-кечкенә шигырьләр, әкиятләр өйрәнү процессына этәрәм. Әкренләп балаларда актив сөйләм, уен осталыклары барлыкка килә.(мимика, ишарә, төрле көчтәге тавыш куллана башлыйлар) Акрынлап, алар уен аралашу процессына күмеләләр.
Үскән саен, балалар сәхнәләштерү уеннарына кызыксынулары арта.Зурлар төркемендә минем алдыма уен-драматизацияләрне үзләштерергә ярдәм итү бурычы басты. Монда катлаулы эчтәлек, оригиналь тел чаралары белән сөйләшүче кызыклы геройлар бар.

Театраль эшчәнлек сөйләмне үстерү өчен түбәндәге мәсьәләләрне үз алдына куя:

***Уртанчылар төркемендә***:

1) Сүзлек байлыгын арттыру һәм активлаштыру.
2) Геройларның, предметларның, декорацияләрнең урынын билгели һәм таба белүне формалаштыру.
3) Сузык һәм тартык авазларның дөрес әйтлешен ныгыту.
4) Сүзләрнең һәм сүтезмәләрнең дөрес әйтелеше өстендә эшләү.
5) Сөйләмнең интонацияле һәм сәнгатьле булуы өстендәэшләү.
6) Театраль эшчәнлек ярдәмендә балаларның диалогик сөйләмен үстерү.

***Олылар төркемендә :***

1) Исемнәр,сыйфатлар, фигыльләр , бәйлек сүзләр ярдәмендә балаларның сүзлек запасын баетуны дәвам итү.
2) Сәнгатьле сөйләмне камилләштерү.
3) Балаларны кыек һәм туры сөйләмне кулланырга өйрәтүне дәвам итү.
4) Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү.
5) Олылар ярдәменнән башка сәнгатьле итеп бәйләнешле сөйләмне куллануны булдыру.

***Мәктәпкә әзерлек төркемендә:***

1) Балаларның сүзлек байлыгын сөйләмдә куллануларын активлаштыруны дәвам итү.

2) Балаларның сузлек байлыгында предметларны, исемнәрне, сыйфатларны, фигыльләрне атаучы сүзләрне арттыру.
3) Барлык авазларны дөрес әйтү,дөрес дикция, сәнгатьле сөйләм өстендә эш.
4) Диалогик һәм монологик сөйләмне камилләштерү.
5) Дөрес сөйләү культурасын тәрбияләү.

Татар телен өйрәтү шөгельләрендә театраль эшчәнлекне оештыру өчен балалар белән түбәндәге чараларны кулланабыз:
-маскалар,
-костюмнар,
-бармак театры,
-өстәл театры,
-курчак театры,
-“Курчаклар  өе”дигән дидактик уен.

“Курчаклар  өе” дигән дидактик уенны балалар бигрәк тә яратып уйныйлар.Үзара уйнаганда диалогик формада сөйләшеп, кызыклы театр килеп чыга.

Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыра, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арта, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туа. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: театраль эшчәнлек ярдәмендә бала, үзе дә сизмәстәнән, татар теле мохитенә чума.Татарча сөйләшә, аралаша башлый, әңгәмә корырга өйрәнә, бәйләнешле сөйләм теле үстерелә. Театраль эшчәнлек ярдәмендә балаларны татар теленә өйрәтү уңышлы нәтиҗәләргә китерә. Балаларның татар теленә карата мәхәббәте, кызыксынуы арта.

Мин киләчәктә дә  балалар бакчасында балаларны татар теленә өйрәтүдә театраль эшчәнлекне куллануны дәвам итәчәкмен.